ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 103 2022 ел, 16 февраль

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» 15.12.2020 ел, № 23 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрүне тәртипкә салу максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007 ел, 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы нигезендә Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрү тәртибенә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә хакында» 15.12.2020 ел, № 23 карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

а) муниципаль хезмәтнең аерым вазыйфаларына билгеләп куелганда, вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булса;

б) муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы, өлкән һәм кече вазыйфалары төркеменә керүче муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләнгәндә.»

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе К.К.Гыйлманов